


Менә алар – жиребезне эшкәртvчеләр һәм туган жиребезне саклаучылар. Жир тоткалары, аны туендыручылар дип атаучылар. Фотода Исмәгыйлевларнын оч абыйсы: Фаиль, Рафаэль, Фатыйх (сулдан унга). Алар Мордовиябезнен Ләмберә районы «Октябрьская» агрофирмасында очесе дә механизатор булып эшлиләр.
Олкәннәре - Рафаэль, әлегә кадәр яше һәм сәламәтлеге кушканчы иген игкән, ягъни комбайнчы булып эшләгән.       Хәзер Ләмберә кырларында жир сорә, чәчv чәчә.
Фаильләре - экскаваторчы, анын эше спецификалы. Фатыйхлары да иген vстерv белән мәшгуль: унышнын югарысын vстерv очен  басуга органик ашлама чыгаруда мәшгуль.
Агрофирманын мастерскойлар модире Михаил Михайлович Милаев та Исмаиловларнын барлык абый-энеләре югары класслы белгечләр; теләсә нинди эш бирсән дә баш тартмый торган хезмәткәрләр булулары турында дәлилләп сойли.
Исмаиловлар гаиләсе ишле – алты бала тәрбияләнеп vскәннәр. Оч лачын тосле ир-егетнен кvбәләк кебек матур бертуган апа-сенелләре горләтеп vскәннәр. Матур гаиләләре, vзара матур монәсәбәттә алар - тату яшиләр. Алда торган бәйрәмне бик тә котәләр. «Без һәр сабантуйда катнашып киләбез, – ди энеләре исеменнән Рафаэль. – Әмма быел ул vзенчәлекле бәйрәм: Ботенроссия авыл Сабантуе! Әле житмәсә, безнен Аксёново авылыбызда vтә. Бу бәйрәм программасында, игълан ителгәнчә, безне кызыксындырган ат чабышлары белән корәш бәйгеләре каралган. Без барыбыз да теге яки бу уен торләренен зур һәвәскәрләре. Шуна да озелеп котәбез».
Аксёново халкы Сабантуйнын туган авыллары очен зур файда китерvен билгеләп vтә. Аерым алганда, тозекләндерv турында cvз бара. Әйтик, Рафаэль Исмаилов «Яшьләр» урамы буенча ныклап тозекләндерелгән кvпфатирлы йортта яши. Урамнары матурланып киткән: яктырту vткәрелгән, тротуарлар һәм бордюралар ясалган. Бәйрәмчә киенгән урам каршы алачак Сабантуйны.
Алар, чыннан да, намус белән эшлиләр һәм рәхәтләнеп ял да итәргә тиешләр, мәсәлән Ботенроссия кvләмендәге Сабан туе кебек vзенчәлекле бәйрәмдә, дип ассызыклыйлар абыйлы-энеле Рафаэль, Фаиль,Фатыйх Исмаиловлар.

**әзерләде Наилә НАСЫРОВА**